ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ

# Сабантуй





Сәлам, дускай!




Сине иң күңелле һәм матур татар бәйрәме — Сабан туена чакырабыз!



Сабан туен бик борынгы заманнардан ук бәйрәм итәләр. Бу бәйрәм язгы кыр эшләре тәмамлануга багышланган.



«Туй» сүзе бәйрәм мәгънәсен белдерә, димәк, ул «сабан бәйрәме» була.

Элек Сабан туен яз көне бәйрәм иткәннәр, хәзер — җәй башында.

Сабан туенда балалар һәм өлкәннәр бергәләп күңел ача, сыйлана, уйный-көлә, җырлый-бии.



Сабан туеның борынгылыгын язма истәлекләр дә раслый. Татарстан Республикасының Әлки районы Иске Сәлмән авылында бәйрәм турында язулы 1292 елгы таш сакланган.

Бәйрәм кунакларын традицион рәвештә милли татар ризыгы — чәкчәк белән каршы алалар.



Син үз халкыңның нинди бәйрәмнәрен беләсең?



Сабан туе — татарларның зур бәйрәме. Аны бик көтеп алганнар һәм алдан ук әзерләнгәннәр.



Кызлар берничә ай буе матурлап кулъяулыклар, сөлгеләр, күлмәкләр чиккән.



Бәйрәм алдыннан егетләр, атлар җигеп, гармун уйный-уйный, бөтен авылны әйләнеп чыга. Һәр йорт янында туктап, бүләккә сөлгеләр, яулыклар һәм башка әйберләр җыялар.

Аларны Сабан туенда җиңүчеләргә һәм уеннарда катнашучыларга бирәләр.





Мәйданда ничә кыз һәм егет барлыгын сана.

Кара әле, мәйдан ничек кайнап тора!

Бәйрәмдә нинди уеннар, ярышлар уза? Аларны санап чык.



Биредә һәркем үзенә ошаган уенкөлке, шөгыль таба ала. «Мәйдан» сүзе фарсы теленнән кергән. Сабан туе уздырыла торган урынны да аңлата.

Игътибарлылыгыңны тикшереп карыйк әле. Бу рәсемдә Сабан туена килгән куянны тап.





Төп ярыш, әлбәттә, татарча көрәш, яки билбаулы көрәш.

Җиңүчегә кыйммәтле бүләк — чып-чын тәкә бирәләр.



Гадәттә бәйрәм ат чабышыннан башлана. Җайдаклар 8–12 яшьлек малайлар яки өлкән ир-атлар булырга мөмкин.

Җиңүчегә иң матур сөлгене бүләк итәләр.





Сабан туенда һәркем катнаша алырлык күңелле уеннар бик күп:



— кашык кабып йөгерү,
— күзне бәйләп чүлмәк вату,
— капчык киеп йөгерү,
— катыктан акча эзләү һәм башкалар.

Әби-бабайлар әйтүенчә, бәйрәм никадәр күңелле узса, уңыш та шулкадәр мулрак булачак.



Сабан туе — татарларның иң яраткан бәйрәме.

Сабан туен татарлар яшәгән һәр җирдә бәйрәм итәләр. Ул Татарстандагы авыллар, районнар һәм шәһәрләрдә генә түгел, Россиянең күп кенә төбәкләрендә, шулай ук



Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Австралия, Казахстан, Үзбәкстан, Франция, Германия, Төркиядә һәм башка бик күп илләрдә уза.

Сабан туе ЮНЕСКОның матди булмаган мәдәни мирас исемлегенә кертелгән.

UNESCO




Сабан туе — татар халкының гореф-гадәтләрен саклый торган мөһим бәйрәм.



Ул һәркемне якынайта, нәниләрне һәм өлкәннәрне, төрле милләт һәм төрле диндәге халыкларны берләштерә.

